УПРАВЛЕНИЕ ЗАГС
КАБИНЕТА МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Улица Ахтямова, дом 14,
город Казань, 420021

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫНЫҢ
ГХАТ ИДАРӘСЕ
Әхтәмов урамы, 14 нче йорт,
Казан шәһәре, 420021

Тел./ факс: (843) 293-14-89, zags@tatar.ru, zags.tatarstan.ru

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**Казан ш.**

**20.02 2023 ел.** **№ 11**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсенең «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына керүгә) конкурс үткәрү турында» 2021 елның 16 апрелендәге 28 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына керүгә) конкурс үткәрү турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Норматив хокукый актны «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) администрациясе турында» 2023 елның 4 февралендәге ПУ-68 номерлы Указына туры китерү максатларында боерык бирәм:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсенең «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына керүгә) конкурс үткәрү турында» 2021 елның 16 апрелендәге 28 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан

хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына керүгә) конкурс үткәрү турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.3 пунктның икенче абзацында «хокукый һәм кадрлар эше бүлеге» дигән сүзләрне «хокукый, оештыру һәм кадрлар эше бүлеге» сүзләренә алмаштырырга;

1.4 пунктта «хокукый һәм кадрлар эше бүлеге» сүзләрен «хокукый, оештыру һәм кадрлар эше бүлеге» сүзләренә алмаштырырга;

2.4 пунктның беренче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты» сүзләренә алмаштырырга;

2.12 пунктта «хокукый һәм кадрлар эше бүлеге» сүзләрен «хокукый, оештыру һәм кадрлар эше бүлеге» сүзләренә алмаштырырга;

4.2 пунктның беренче абзацында «хокукый һәм кадрлар эше бүлеге белән» дигән сүзләрне «хокукый, оештыру һәм кадрлар эше бүлеге белән» сүзләренә алмаштырырга;

4.5 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.5. Беренче этапта хокукый, оештыру һәм кадрлар эше бүлеге түбәндәгеләрне оештыра:»;

4.10 пунктның икенче абзацында «хокукый һәм кадрлар эше бүлеге» сүзләрен «хокукый, оештыру һәм кадрлар эше бүлеге» сүзләренә алмаштырырга;

4.12.1 пунктның икенче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты» сүзләренә алмаштырырга;

4.12.1 пунктның дүртенче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты» сүзләрен тиешле килеш кушымчаларында «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты» сүзләренә алмаштырырга;

4.12.5 пунктның өченче абзацында «хокукый һәм кадрлар эше бүлеге белән» дигән сүзләрне «хокукый, оештыру һәм кадрлар эше бүлеге белән» сүзләренә алмаштырырга.

Идарә җитәкчесе Г.Р.Нигъмәтуллина